ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 елның «01» ноябреннән № 316

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы үзәге – Яңа Чишмә авылыннан 11 километрдан ераграк урнашкан авыл торак пунктларына беренче чиратта кирәкле товарларны китерүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен кулланучылар кооперациясе оешмаларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 03 июнендәге 242 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы составына керүче, ерак торак пунктларда яшәүче авыл халкын беренче чиратта кирәкле товарлар белән тәэмин итү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Субсидияләр бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга, шул исәптән, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар җитештерүче, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне башкаручы физик затларга субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга салучы муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында, һәм Россия Федерциясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм кайбер актларның нигезләмәләрен гамәлдән алынган дип санау турында» Россия Федерциясе Хөкүмәтенең 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы район үзәкләреннән 11 километрдан ераграк урнашкан Татарстан Республикасы авыл торак пунктларына кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан

Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2017 елның 20 ноябрендәге 887 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы үзәге – Яңа Чишмә авылыннан 11 километрдан ераграк урнашкан авыл торак пунктларына беренче чиратта кирәкле товарларны китерүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен кулланучылар кооперациясе оешмаларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 03 июнендәге 242 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 бүлекнең 1.7 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

« - сайлап алуда катнашучы үзләренә карата экстремистик эшчәнлеккә яисә терроризмга катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә йә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә (әгәр мондый таләпләр хокукый актта каралган булса) булырга тиеш түгел.»;

1.2. 2 бүлектәге 2.6 пунктының 2 абзацына «, шулай ук аларны бирү нәтиҗәләре» сүзләрен өстәргә;

1.3. 2 бүлектәге 2.6 пунктның 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «субсидияләр алучыларга һәм затларга карата, субсидияләр бирүче бюджет акчаларын баш бүлүчегә (бүлүчегә) тикшерүләрне гамәлгә ашыру, алар тарафыннан субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән аларны бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268-1 һәм 269-2 статьялары нигезендә дәүләт (муниципаль) финанс тикшерүе органнары тарафыннан тикшерүләрне гамәлгә ашыру хокукы»;

1.4. 4 бүлектә:

«контроль» сүзен «контроль (мониторинг)» сүзләренә алмаштырырга;

«, максатларны» сүзен төшереп калдырырга.;

1.5. 1 бүлекнең 1.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты бердәм порталда («электрон бюджет» (алга таба - «Электрон бюджет») иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең интеграцияләнгән дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба - «Электрон бюджет» системасы) сайлап алуны үткәрү турында игълан итү датасын, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru сайлап алуны үткәрү турында игълан итү хакында түбәндәгеләрне күрсәтеп урнаштырырга:

сайлап алуны үткәрү сроклары, шулай ук берничә этапны сайлап алу мөмкинлеге турында мәгълүмат, аларны үткәрү вакыты һәм тәртибе (кирәк булганда);

Сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (гаризаларын) кабул итүне төгәлләү датасы сайлап алуны үткәрү турында игълан урнаштырылган көннең иртәгесеннән 30 календарь көннән дә иртәрәк була алмый.

бюджет акчаларын алучы буларак баш бүлүченең яисә хокукый акт нигезендә сайлап алу үткәрә торган (хокукый акт белән каралган очракта) башка оешманың исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почтасы адреслары;

субсидияләр бирү нәтиҗәләре;

сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган «Электрон бюджет» системасы битләренең домен исемен һәм (яисә) күрсәткечләрен яисә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге башка сайтны;

әлеге Тәртипнең 1.4 һәм 1.7 пунктлары һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеге нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләр;

сайлап алуда катнашучылар тарафыннан гаризалар бирү тәртибе һәм әлеге Тәртип нигезендә сайлап алуда катнашучылар тарафыннан бирелә торган гаризаларның формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләр;

сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен(гаризаларын) кайтарып алу тәртибе, тәкъдимнәрен(гаризаларын) кире кайтару өчен нигезләрне дә билгели торган тәкъдимнәрен(гаризаларын)кире кайтару тәртибе, сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәренә(гаризаларына) үзгәрешләр кертү тәртибе;

әлеге Тәртип нигезендә сайлап алуда катнашучыларның гаризаларын карау һәм бәяләү кагыйдәләре;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алу үткәрү турында игълан нигезләмәләренә аңлатма бирү тәртибе, мондый тәкъдим итүнең башлану һәм тәмамлану вакыты;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) субсидия бирү турындагы килешүне (алга таба – килешү) имзаларга тиешле вакыт аралыгы;

сайлап алуның җиңүчесе (җиңүчеләре) килешү төзүдән баш тартуын тану шартлары;

2025 елның 1 гыйнварыннан сайлап алуны үткәрү нәтиҗәләре турында белдерүне бердәм порталда (сайлап алу «Электрон бюджет» системасында үткәрелгән очракта) яисә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителгән башка сайтта (бердәм порталда сайт битен урнаштыру белән), шулай ук, кирәк булган очракта, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бюджет акчаларын алучы буларак баш бүлүченең рәсми сайтында урнаштыру датасы күрсәтелә, ул сайлап алу җиңүчесен билгеләү көненнән соң килүче 14 нче календарь көненнән дә соң булмаска тиеш.

Сайлап алуны үткәрү, гаризаларны карау нәтиҗәләре, сайлап алуда катнашучылар һәм сайлап алу нәтиҗәләре, шул исәптән сайлап алуда катнашучылар белән төзелгән килешүләр турында мәгълүмат керү мөмкинлеге чикләнгән мәгълүмат булып тора.»

1.6. 1бүлекнең 1.7 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«сайлап алуда катнашучы үзләренә карата экстремистик эшчәнлеккә яисә терроризмга катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә йә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә (әгәр мондый таләпләр хокукый актта каралган булса) булырга тиеш түгел.»;

1.7. 4 бүлекнең 4.1 пунктын; 3 кушымтаның 1.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидияләр алучыларга һәм затларга карата, субсидияләр бирүче бюджет акчаларын баш бүлүчегә (бүлүчегә) тикшерүләрне гамәлгә ашыру, алар

тарафыннан субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән аларны бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268-1 һәм 269-2 статьялары нигезендә дәүләт (муниципаль) финанс тикшерүе органнары тарафыннан тикшерүләрне гамәлгә ашыру хокукы»;

1.8. 2.6 пунктта «субсидияләр бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен үтәүне финанс контроле Башкарма комитеты һәм аңа карата» сүзләрен «субсидияләр бирә торган бюджет акчаларын баш бүлүче (бүлүче) тарафыннан субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын үтәү, шул исәптән аларны бирү нәтиҗәләренә ирешү, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268_1 һәм 269_2 статьялары нигезендә дәүләт (муниципаль) финанс тикшерүе органнары тарафыннан тикшерү өлешендә» сүзләренә алмаштырырга;

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

а) 1 бүлекнең 1.6 пунктындагы беренче, алтынчы һәм ундүртенче абзацларның нигезләмәләре, 2025 елның 1 гыйнварыннан башлап Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан (җирле бюджетлардан) бирелә торган башка субсидияләргә карата кулланыла.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авылыннан 11 километрдан ераграк урнашкан һәм аз халыклы авыл пунктларына кулланучылар кооперациясе оешмалары тарафыннан беренче чиратта кирәкле товарлар китерүгә бәйле чыгымнарының бер өлешен каплау өчен юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш) субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 15 октябрендәге 251 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 26 маендагы 159 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып

чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов